КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 декабрь г.Казань № 1215

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 16 июль, 521 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 16 июль, 521 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 22 март, 212 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында, күрсәтелә торган хезмәтләр турында һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау буенча башкарыла торган эшләр турында, аларны күрсәтү һәм үтәү тәртибе турында, аларның хакы турында, коммуналь хезмәтләргә күрсәтелә торган бәяләр (тарифлар) турында мәгълүмат урнаштыру;»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) заявка биргән датага кадәрге айның беренче числосына салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин